КАРАР
Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Кадрәк авыл җирлеге Советы

№ 1 28.10.2025

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы "Кадрәк авыл җирлеге" Советының «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы "Кадрәк" авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва итүче гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны, шулай ук Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы "Кадрәк" авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны тәкъдим итү турында Нигезләмәне раслау»21.11.2014 № 4 карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясенең 10.07.2023 № 286-ФЗ «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законы, Россия Федерациясенең 01.04.2022 № 90-ФЗ «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законы, Татарстан Республикасының 26.12.2020 № 97-ЗРТ «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Кадрәк авыл җирлеге Советы карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Кадрәк авыл җирлеге Советының 2014 елның 21 ноябрендәге "ТР, Минзәлә муниципаль районы «Кадрәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва итүче гражданнарның керемнәре, милке һәм милек характерындагы йөкләмәләре турында, шулай ук ТР, Минзәлә муниципаль районы «Кадрәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, милке һәм милек характерындагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү тәртибен раслау турында» № 4 карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 16 пунктның 2 абзацында «яки аларның тулы булмаган яки дөрес булмаган мәгълүматлар бирүе» сүзләрен «үз чыгымнары турында мәгълүматлар, федераль законнар белән билгеләнгән очраклардан тыш, алдан ук тулы булмаган мәгълүматлар бирү, яки алдан ук дөрес булмаган мәгълүматлар бирү» сүзләре белән, «яки үзләренең ир (хатын) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында мәгълүматларны бирмәү яки алдан ук тулы булмаган яки дөрес булмаган мәгълүматлар бирү» сүзләрен «яки үзләренең ир (хатын) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында мәгълүматларны бирмәү, федераль законнар белән билгеләнгән очраклардан тыш, алдан ук тулы булмаган мәгълүматлар бирү, яки үзләренең ир (хатын) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында алдан ук дөрес булмаган мәгълүматлар бирү» сүзләре белән алыштыру.

1.2. 7 пунктының пунктчасында "оешмалар)" сүзеннән соң ", цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта" сүзләре белән тулыландырырга;

1.3. 6 пунктының пунктчасында ", акцияләр" сүзен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе Х.Х.Нәбиуллин